| ЛЕНИНОГОРСКИЙ ГОРОДСКОЙ СОВЕТ МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ ГОРОД ЛЕНИНОГОРСК ЛЕНИНОГОРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА | ЛЕНИНОГОРСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ЛЕНИНОГОРСК ШӘҺӘРЕ МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ ЛЕНИНОГОРСК ШӘҺӘРЕ СОВЕТЫ |
|---|---|

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

31.07.2024 г.Лениногорск № 200

Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Лениногорск шәһәре муниципаль берәмлеге Советының «Физик затлар мөлкәтенә салым турында» 2015 елның 27 октябрендәге 17 номерлы карарына (27.09.2018 ел, № 163, 13.12.2018 ел, № 177, 03.03.2023 ел, № 119 үзгәрешләр белән) үзгәрешләр кертү хакында

Россия Федерациясе Салым кодексының 406 статьясы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының Лениногорск шәһәре муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының Лениногорск шәһәре муниципаль берәмлеге Советы КАРАР БИРДЕ:

1. Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Лениногорск шәһәре муниципаль берәмлеге Советының «Физик затлар мөлкәтенә салым турында» 2015 елның 27 октябрендәге 17 номерлы карарына (27.09.2018 ел, № 163, 13.12.2018 ел, № 177, 03.03.2023 ел, № 119 үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1) карарның 2 пунктындагы 4 пунктчасын түбәндәге эчтәлекле 4 нче абзац белән тулыландырырга:

«Гомуми мәйданы 1000 квадрат метрдан артыграк булган административ-эшлекле үзәкләргә һәм сәүдә үзәкләренә (комплексларына)

һәм алардагы Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы күрсәтмәсе белән раслана торган исемлеккә кертелгән урыннарга карата 1,2 процент;».

2) карарның 2 пунктындагы 4 пунктчасының 4 һәм 5 абзацларын тиешенчә 5 һәм 6 абзацлар дип санарга.

2. Әлеге карарны Лениногорск муниципаль районының рәсми сайтында (https://leninogorsk.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (https://pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карар Россия Федерациясе Салым кодексының 5 статьясы нигезендә үз көченә керә һәм 2025-2027 еллар салым чорларына гамәлдә була.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплыгымда калдырам.

Лениногорск шәһәре
муниципаль берәмлеге башлыгы,
Лениногорск шәһәре мэры

Р.Г. Хөсәенов